КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 декабрь

г.Казань

№ 1128

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 июнь, 525 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 666 нчы; 2017 ел, 21 март, 162 нче; 2017 ел, 13 июль, 490 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән һәм башкарган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләренә» сүзләрен «физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләре (классификаторлары), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлеге (классификаторы), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләре (классификаторлары) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләрен (классификаторларын), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәте күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган эшләрнең федераль исемлекләрен (классификаторларын) формалаштыру, аларны алып бару һәм раслау турында» 2017 ел, 30 август, 1043 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә раслана.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлеге (классификаторы), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлеген (классификаторын), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, формалаштыру, аларны алып бару һәм раслау тәртибен раслау турында» 2018 ел, 18 июль, 578 нче нигезендә раслана.»;

3.2 пунктның икенче абзацында «дәүләт, муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең төп (тармак) исемлегендә хезмәтнең бердәй коды булган ведомство хезмәтләренең» сүзләрен «физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләре (классификаторлары), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлеге (классификаторы), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 декабрь, 1095 нче; 2012 ел, 19 июнь, 525 нче; 2012 ел, 20 декабрь, 1107 нче;

2015 ел, 15 сентябрь, 666 нчы; 2017 ел, 21 март, 162 нче; 2017 ел, 13 июль, 490 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибендә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләренә» сүзләрен «физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләре (классификаторлары), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлеге (классификаторы), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга;

3.9 пунктта таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Агрегацияләнгән индикатор мәгънәсе | Бәянең аңлатмасы |
|---|---|
| 0,95 – 1,0 | хезмәт күрсәтү сыйфаты дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына туры килә |
| 0,85 – 0,94 | хезмәт күрсәтү сыйфаты тулаем алганда дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына туры килә |
| 0,71– 0,84 | хезмәт дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын бозып күрсәтелә, әмма аны төзәтеп була |
| 0 – 0,70 | хезмәт күрсәтү сыйфаты дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына туры килми». |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 679 нчы; 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2016 ел, 19 декабрь, 951 нгче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат

хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүне физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлегеннән (классификаторыннан) чыгару;».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 5 сентябрь, 638 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1020 нче, 2016 ел, 15 апрель, 228 нче, 2016 ел, 29 декабрь, 1029 нчы, 2017 ел, 25 март, 180 нче, 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 2 пунктында «муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) ведомство исемлекләрен» сүзләрен «муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль йөкләмләрне» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенең 10 графасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомство исемлеген булдырганда күләм күрсәткече исеме/муниципаль биремне булдырганда күләм күрсәткече исеме, үлчәү берәмлеге».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 974 нче, 2016 ел, 14 гыйнвар, 12 нче, 2016 ел, 2 ноябрь, 807 нче, 2016 ел, 31 декабрь, 1094 нче, 2017 ел, 27 июнь, 441 нче, 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче, 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 апрель, 296 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

каарарның 2 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен» сүзләрен «дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлегенең 10 графасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт йөкләмәсен формалаштырганда күләм күрсәткече исеме, үлчәү берәмлеге».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 апрель, 205 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның беренче абзацында «түләүле нигездә» сүзләре алдыннан «дәүләт йөкләмәсе кысаларында» сүзләрен өстәргә;

5 пунктның беренче абзацында «субсидия (алга таба – субсидия) бирүгә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Дәүләт йөкләмәсе физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләрендә (классификаторларында) (алга таба – бөтенроссия база исемлекләре), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлегендә (классификаторында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, (алга таба – төбәк исемлеге) булган дәүләт учреждениеләренең төп эшчәнлек төрләре сыйфатында билгеләнгән дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) формалаша.

10 пунктның дүртенче һәм алтынчы абзацларында «ведомстволар исемлегенә кертелгән» сүзләрен «дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «база (тармак) исемлектә» сүзләрен «бөтенроссия база (тармак) исемлегендә (классификаторында)» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктка «(әгәр дәүләт бюджет яки автоном учреждение уставы белән эшләр башкаруга норматив чыгымнар билгеләүнең бүтән тәртибе билгеләнмәсә).» сүзләрен өстәргә;

34 пунктның дүртенче абзацында «ведомстволар исемлегенә кертелгән» сүзләрен «дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2017 ел, 13 июль, 485 нче

карары белән расланган Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «ведомственные перечни государственных услуг, работ» сүзләрен «физик затлар күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләре (классификаторлары), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бөтенроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең һәм күрсәтү һәм үтәү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) каралган эшләрнең төбәк исемлеге (классификаторы), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак алып бару предметлары буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «әлеге Тәртип,» сүзләреннән соң «күрсәтелә торган хезмәтләрдән чыгып, пландагы һәм гамәлдәге чыгымнарны күрсәтеп,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин